**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ**
# КАРАРЫ

Татарстан Республикасында тарифларны җайга салуны цифрлаштыру турында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе Р.В. Гайнетдиновның һәм Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары Б.Ф. Габдрахмановның Татарстан Республикасында тарифларны җайга салуны цифрлаштыру турындагы мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында тарифларны җайга салуны цифрлаштыру турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы территориясендә ресурслар белән тәэмин итүче оешмаларның икътисадый нәтиҗәлелеген тәэмин итү, тарифларны формалаштыруда ачыклыкка ирешү һәм халыкка күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту өчен кирәкле шарт буларак тарифларны җайга салуны цифрлаштыруны гамәлгә кертүнең актуальлеген һәм ихтыяҗлыгын билгеләп үтәргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына түбәндәгеләр буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетына ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә:

гражданнарның гамәлдәге тарифлар турындагы мәгълүматтан оператив файдалана алуы сервисларын үстерүдә, МАХ илкүләм мессенджерында чат-бот эшләүне кертеп;

«ГосПромпт» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салуда куллану максатында аның мөмкинлекләрен киңәйтүдә.

4. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетына Монополиягә каршы федераль хезмәт белән бергә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. «Тарифларны җайга салуның бердәм мәгълүмати-аналитик системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба –

ФГИС «ТАРИФ») аңа электрон документларны саклау мөмкинлекләрен өстәү юлы белән киңәйтү, шулай ук ФГИС «ТАРИФ»тан Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимиятенең тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендәге органнары һәм Монополиягә каршы федераль хезмәт арасында мәгълүмат алмашу өчен бердәм канал буларак файдалану мөмкинлеген карарга.

4.2. ФГИС «ТАРИФ»ны үстерү һәм тикшерү буенча эшче төркемнәрдә катнашуны дәвам итәргә.

5. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгына Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты белән бергә гражданнарга тарифлар буенча кабул ителә торган карарлар, тарифларны исәпләү методикасы һәм аларны формалаштыру механизмнары турында, шулай ук Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының социаль челтәрләрдәге һәм мессенджерлардагы рәсми элемтә каналлары булуы хакында мәгълүмат бирүне дәвам итүне тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 17 декабре
№ 137-VII ДСП